КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 19 апрель г.Казань № 369

Татарстан Республикасында ясалма интеллект технологияләреннән файдалану турында

Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә ясалма интеллектны үстерү турында» 2019 елның 10 октябрендәге 490 номерлы Указы нигезендә, ясалма интеллект технологияләре өлкәсендә ышанычлы мохит булдыру, Татарстан Республикасында ясалма интеллект технологияләрен булдыруда, гамәлгә кертүдә һәм алардан файдалануда алымны унификацияләү максатларында, шулай ук Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең мәнфәгатьләрен һәм хокукларын яклау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Түбәндәгеләрне (карарга теркәләләр) расларга:

Гражданнарның, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның ясалма интеллект технологияләре өлкәсендәге электрон хезмәттәшлеге турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары эшчәнлегенә кертелгән ясалма интеллект технологияләре турында мәгълүматны гавами урнаштыруга таләпләр.

2. Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органнарына, “Татарстан Республикасын цифрлы трансформацияләү үзәге” дәүләт казна учреждениесенә, шулай ук федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарына, Татарстан Республикасындагы җирле үзидарә органнарына, оештыру-хокукый рәвешенә бәйсез оешмаларга, шәхси эшмәкәрләргә Татарстан Республикасында ясалма интеллект технологияләре өлкәсендә проектлар һәм (яисә) тәкъдимнәр эшләгәндә әлеге карарга таянырга тәкъдим итәргә.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры                                                                                    А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 19 апрель, 369 нчы
карары белән расланды

Гражданнарның, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның ясалма интеллект технологияләре өлкәсендәге электрон хезмәттәшлеге турында
нигезләмә

## I. Гомуми нигезләмәләр

Әлеге Нигезләмә гражданнарның, Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнарының, федераль башкарма хакимият органнарының Татарстан Республикасы буенча территориаль органнарының, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органнарының һәм оешмаларның ясалма интеллект технологияләре (алга таба - ЯИТ) өлкәсендәге багланышлары механизмын төзү максатларында эшләнде.

## II. Терминнар һәм билгеләмәләр

Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төп төшенчәләр кулланыла:

Система - dovod.tatar адресы буенча урнашкан «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә ясалма интеллект өлкәсендә бердәм тәрәзә» мәгълүмат системасы;

Кулланучы - Системада теркәлгән физик зат;

хәбәрнамә - ЯИТ өлкәсендәге тәкъдим яисә Системаны кулланып ЯИТ мәсьәләләре буенча шикаятьләр;

хәбәрнамә категориясе - анда билгеләнгән проблема яисә тәкъдим нигезендә хәбәрнамә билгесе буенча берләштерелгән мөрәҗәгатьләрнең тематик төркеме;

верификация - хәбәрнамәләрне карау барышына башлангыч экспертиза һәм мониторинг ясау;

Система модераторы - мөрәҗәгатьләрне верификацияләүне гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасын цифрлы трансформацияләү үзәге» дәүләт казна учреждениесе;

Башкаручы - Татарстан Республикасы дәүләт хакимиятенең башкарма органы, федераль башкарма хакимият органының Татарстан Республикасы буенча территориаль органы, Татарстан Республикасында җирле үзидарә органы, җаваплы вазыйфаи затлар йөзендә, шулай ук мөрәҗәгатьләрне карауны гамәлгә ашыручы башка оешмалар.

III. Хәбәрнамәләрне бастырып чыгару һәм карау тәртибе

3.1. Кулланучы Система модераторына Системада рус яки татар телендә махсус форманы тутыру юлы белән хәбәрнамә җибәрә.

3.2. Хәбәрнамә текстында цензурасыз яисә хурлыклы әйтемнәр, гражданнарның тормышына яисә сәламәтлегенә куркыныч янаулар, экстремистик эшчәнлекне гамәлгә ашыруга чакырулар булырга тиеш түгел.

3.3. Кулланучының хәбәрендә түбәндәге мәгълүмат булырга тиеш:

хәбәрнамәнең исеме;

хәбәрнамәнең тасвирламасы;

Система хәбәрнамәләре категорияләре исемлегенә туры килүче хәбәрнамә категориясе;

Кулланучы турында белешмәләр (фамилия, исем, атасының исеме (соңгысы - булган очракта)).

3.4. Әлеге Нигезләмәнең 3.3 пунктында каралган мәгълүматка өстәмә буларак, хәбәрнамәдә Кулланучының шәхси мәгълүматларын эшкәртүгә ризалык була, шулай ук хәбәрнамәгә беркетелә торган электрон файллар рәвешендә өстәмә материаллар булырга мөмкин.

3.5. Верификация процедурасы Татарстан Республикасы Дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы тарафыннан раслана торган ЯИТ мәсьәләләре буенча тәкъдимнәрне бәяләү кагыйдәләре нигезендә файдаланучыдан хәбәрнамә алган көннән алып 10 эш көне эчендә Система Модераторы тарафыннан үткәрелә (алга таба - бәяләү кагыйдәләре).

Верификация процедурасы тәмамланганчы, хәбәрнамәгә «Карауда» статусы бирелә. Бу статустагы хәбәрнамә Башкаручыларга җибәрелми.

Верификация процедурасы нәтиҗәләре буенча хәбәрнамәгә түбәндәге статусларның берсе бирелә:

«Верификация үтелмәгән» - расланган бәяләү кагыйдәләренә хәбәрнамәдә күрсәтелгән тәкъдимнең туры килмәве турында Система модераторы тарафыннан карар кабул ителгән очракта;

«Верификация үтелгән» - тәкъдим ителгән тәкъдимнең бәяләү кагыйдәләренә туры килүе турында Система модераторы тарафыннан карар кабул ителгән очракта.

Верификация процедурасын үткәргән көннән алып ике эш көне эчендә хәбәрнамә Система модераторы тарафыннан тиешле Башкаручыга карауга җибәрелә.

3.6. Башкаручы хәбәрнамәне Система модераторыннан хәбәрнамә алган көннән алып 14 эш көне эчендә карый һәм аңа түбәндәге статусларның берсен бирелә:

«Планлаштырылган» - әгәр хәбәрнамәдә күрсәтелгән тәкъдимне гамәлгә ашыру хәбәрнамә кергән көннән алып алты айдан да артмаган чорга планлаштырылган булган шартларда Башкаручы тарафыннан хәбәр (шикаятьләрдән тыш) бирелә.

Күрсәтелгән очракта, хәбәрнамәне карау срогы хәбәрнамә статусында күрсәтелгән планлаштырылган чараларны гамәлгә ашыру чорына Башкаручы тарафыннан озайтыла;

«Кире кагылган» - Башкаручыда хәбәрнамәдә күрсәтелгән мәсьәлә буенча карар кабул итү өчен законлы нигезләр булмаган очракта, шул исәптән, аны хәл итү өчен кирәкле чараларны гамәлгә ашыруга финанслау булмаган очракта, раслый

торган документларның реквизитларын күрсәтеп, Башкаручы тарафыннан хәбәрнамәгә бирелә;

«Хәбәрнамә хәл ителде» - хәбәрнамәдә билгеләнгән мәсьәлә Башкаручы тарафыннан асылы буенча хәл ителгәндә хәбәрнамәгә бирелә. Күрсәтелгән статус хәбәрнамәдә билгеләнгән мәсьәләне асылы буенча хәл итмичә генә, Башкаручы тарафыннан Системада урнаштырылган очракта, Кулланучы һәм (яисә) Системаның модераторы тарафыннан кире кагылырга мөмкин.

Хәбәрнамә алынган көннән алып бер эш көне дәвамында хәбәрнамәне карау өчен нигезләр һәм компетенцияләр булмау турында дәлилләнгән аңлатмалар аның тарафыннан Системага кертелгән очракта Башкаручы, аны Система модераторына кире кайтарып, тикшерүгә юнәлтелгән хәбәрнамәне кире кага.

3.7. Кулланучы әлеге Нигезләмәнең 3.6 пунктының беренче абзацында күрсәтелгән хәбәрнамәне карау срогы узгач, Системадагы шәхси кабинетында хәбәрнамә статусы турында мәгълүмат ала. Хәбәрнамәне карау статусы үзгәргәндә, Кулланучы хәбәрнамәне карау статусы үзгәргәннән соң бер эш көне эчендә тиешле мәгълүматны Системадагы шәхси кабинетында ала.

3.8. Система модераторы Башкаручыларга хәбәрнамәне эшкәртү срокларының һәм сыйфатының үтәлешен тикшереп тора.

## IV. Хәбәрнамәләрне карау барышын мониторинглау

4.1. Хәбәрнамәләрне карау барышын мониторинглау әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән тәртиптә Система модераторы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4.2. Әгәр җавап түбәндәгечә булган очракларда Система модераторы хәбәрнамәне кабат карауга кайтара:

формаль характерда, хәбәрнамәдә куелган сорауга җавап бирми, Кулланучы тасвирлаган фактларны раслаганда эшләрне тәмамлау яисә төзәтү сроклары юк;

хәбәрнамәдә күрсәтелгән сорауның асылы буенча кирәкле нигезләрне үз эченә алмый;

Россия Федерациясе законнарын бозып эшкәртелә торган өченче затларның шәхси белешмәләрен үз эченә ала;

гомуми кулланышта булмаган һәм эчтәлеге ачылмаган терминнар һәм (яисә) аббревиатуралар бар.

## V. Татарстан Республикасында ясалма интеллект технологияләрен булдыру, гамәлгә кертү һәм куллану принциплары

5.1. Әлеге принциплар Татарстан Республикасында ЯИТ төзегәндә, гамәлгә керткәндә һәм кулланганда файдаланыла торган база тезисларыннан гыйбарәт.

5.2. Принциплар Россия Федерациясе Конституциясе, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә ясалма интеллектны үстерү турында» 2019 елның 10 октябрендәге 490 номерлы Указы белән расланган 2030 елга кадәр чорга ясалма интеллектны үстерүнең милли стратегиясе, Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясе милли иминлек стратегиясе турында» 2021 елның 2 июлендәге 400 номерлы Указы белән расланган Россия Федерациясе милли

иминлек стратегиясе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2020 елның 19 августындагы 2129-б номерлы боерыгы белән расланган 2024 елга кадәр ясалма интеллект һәм робот техникасы технологияләре өлкәсендә мөнәсәбәтләрне җайга салу концепциясе, шулай ук Россия Федерациясенең башка норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасының башка норматив хокукый актлары нигезендә эшләнде.

5.3. Татарстан Республикасында ЯИТ өлкәсендә проектларны гамәлгә ашыру принциплары:

а) шәхси мәгълүматларның шәхси үзенчәлекләрен бетерү;

б) Татарстан Республикасында ЯИТ өлкәсендә карарларның ачыклыгы һәм аңлаешлылыгы;

в) Татарстан Республикасы халкының барлык төркемнәренә ЯИТ өлкәсендәге сервислардан файдалана алуны тәэмин итү;

г) Татарстан Республикасында ЯИТ өлкәсендәге карарларны мәҗбүри верификацияләү.

5.4. Күрсәтелгән принципларны гамәлгә ашыру механизмы Татарстан Республикасы дәүләт идарәсен цифрлы нигездә үстерү, мәгълүмат технологияләре һәм элемтә министрлыгы боерыгы белән билгеләнә.

---